# Мәктәп хәбәрчесе

**№5 (№18) сентябрь 2020 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

# Мәктәп, без сине бик сагындык!

*/Мөхәррир сүзе /*

## Укуның кадерен белеп яшик!




Булганның кадерен югалткач беләсең, ди халык. Быелгы ел казасы мәктәп тирәсен шомлы, ялгыз итте. Балаларның шат авазы яңгырамавы, дәрескә кыңгырау чыңламавы – иң күңелсез хәлләрдән булды. Читтән торып укып караганнан соң, мәктәпкә йөреп белем алуның да, укытуның да кадерен һәрберебез аңлады. Инде менә сагынып көткән Белем бәйрәме дә килеп җитте. 1-нче сентябрь иртәсендә мәктәп ишегалды балаларның шатлыклы авазына, кыңгырауның яңгыраулы чыңына күмелде.

Хөрмәтле укытучылар, кадерле укучылар! Белем көне – кеше тормышындагы иң зур бәйрәмнәрнең берсе. 1-нче сентябрьнең беренче кыңгыравы аны гомере буе матур хатирә булып озата бара. Һәр заманда да гыйлемсез кеше — җансыз-рухсыз зат кебек саналган. Барыгызны да мәктәп белеменең кирәклеген тоеп, тырышып белем алырга, укуның тәмен татырга, кызыклы фәннәр иленә чакырабыз.

*Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Беренче сентябрь – Белем бәйрәме белән!

Кыңгырау чыңлый үтә дә
Моңлырак итеп быел.
Сагынган укучыларын
Чакыра болай тик бу ел.

Коридорлар бушап калган
Такта, акбурлар эшсез...
Мәктәп тирәсе тынлыктан
Калган бөтенләй өнсез.

Килдек, кыңгырау, килдек
Сагынышып җыелдык.
Белем алуның кадерен
Үзебез дә бик белдек.

Сагындык укытучының
Аркадан сыйпаганын.
Такта янына чакырып
Фән серен аңлатканын.

Булмасын моннан соң
Ялгыз көннәрең синең.
Чакырган дәресләреңнең
Белдек хәзер кадерен.

*/Рәсми хәбәрләр /*

## 2020/2021-нче уку елында мәктәпнең эшчәнлек тәртибе

Яңа 2020/2021-нче уку елын мәктәп гадәти эшчәнлек тәртибендә башлап җибәрде. Шул ук вакытта, яңа короновирус инфекциясе таралу куркынычы зур булганлыктан, мәктәпнең эчке режимында үзгәрешләр дә бар:

- укучылар элеккеге кебек төрле кабинетларга күчеп түгел, ә аерым бер кабинетта гына укыячак;
- бары тик информатика, технология һәм лаборатор эшләр башкарганда химия, физика фәннәре генә үз кабинетларында үткәрелә торган була;
- тәнәфес вакытларында укучыларның мәктәп буйлап ирекле хәрәкәтләнүе чикләнә;
- иртән мәктәпкә кергәндә укучылар, хезмәткәрләр һәм эш буенча килгән чит затларнең тән температурасы контактсыз термометр белән үлчәнеп, махсус журналга теркәлә;
- мәктәп ачылыр алдыннан, көн уртасында һәм дәресләрдән соң техник хезмәткәрләр коридорда һәм бүлмәләрдә дезинфекция чаралары үткәрә.
- көн дәвамында тәнәфес вакытларында бүлмәләрне җилләтеп алу тиешле. Өстәмә рәвештә һаваны бактерия һәм вируслардан зарарсызландыручы “Дезар” җиһазы да эшләтеләчәк;
- ашханә хезмәткәрләре даими саклану маскалары һәм перчаткалардан эшләргә, ә укытучылар укучыларга якын арага килгәндә битләренә саклану маскалары киергә тиеш.

Югарыда китерелгән таләпләрдән тыш, укучыларга бер-берсенә якын арада булып аралашудан сакланырга кирәк. Шул ук вакытта укучыларның саклану маскалары киеп йөрүе ирекле

*Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Рузилә Хәйруллина*

**/Рәсми хәбәрләр /**

## Яңа уку елы башланды

Һәр яңа уку елы мәктәп өчен күпмедер күләмдә яңалык белән башланып китә. Быелгы уку елына килгәндә түбәндәге үзгәрешләрне билгеләп үтергә мөмкин.

2020/2021-нче уку елын мәктәп яшендәге 53 укучы һәм бакча төркемендәге 11 бала белән башлап җибәрдек. Мәктәпнең Иске Татар Әдәмсуы авылындагы филиалында, укучы балалар калмау сәбәпле, бары тик бакча төркеме генә эшләячәк. Анда барлыгы 3 бала тәрбияләнә.

Яшәү урыннары буенча караганда, укучыларның 38-е Түбән Майнаныкы, 5-е Такталыдан, 7-се Иске Әдәмнән, 2-се Яңа Әдәмнән килеп йөриләр. Яңа Әдәм авылына кайткан бер укучы өйдә укыту режимында белем алачак.

Быел 1-нче сыйныфка 4 бала укырга керде. Төп белем баскычын тәмамлаган 7 укучының 4-се 10-нчы сыйныфка калды. Башлангыч сыйныфларда барлыгы 19 бала, урта буын сыйныфларында 29, зур якларда 7 укучы белем ала.

Укытучы кадрларга килгәндә, инглиз теле укытучысы Макарова Ирина Иосифовна үз теләге белән эштән китте. Җәен бала ялына чыккан математика укытучысы Сафиуллина Алсу урынына күп еллар Такталы мәктәбендә хезмәт куйган Зарипов Фәнил Закир улы алынды. Быелгы уку елы башы мәктәпкә яшь белгеч кайту белән куанычлы булды. Җәен авылның мәдәният йорты мөдире булып урнашкан үзебезнең 2015-нче елгы чыгарылыш укучысы Нәҗметдинова Ләйсән, өстәмә рәвештә мәктәптә сәнгать дәресләрен алып барачак.

Быелгы уку елында укучыларның мәктәптә туклануына кагылышлы үзгәрешләр дә бар. Яңа чыккан федераль закон нигезендә, башлангыч сыйныфларда укучылар көненә бер тапкыр кайнар аш белән бушлай тәэмин ителәчәк.

***Мәктәп директоры Рафик Насыйров***

## Һөнәри бәйрәмегез белән, тәрбияче апалар!




Балалар бакчасы һәрвакыт күңелле бер балачак иле булып күз алдында кала. Ул илдә һәрчак назлы елмайган тәрбияче апалар, мавыктыргыч уеннар, кызыклы, тылсымлы әкиятләре белән тулыландырылган көндәлек тормышы башлана сабыйның. Бу вакытның ничек үтүе, балага булган мөнәсәбәтнең җылы булуы бик мөһим. Ә безнең тәрбияче апаларыбыз, барлык бакча хезмәткәрләре шундыйлардан. Нәниләрнең һәрберсе сездәге ямьне, гүзәллекне күреп үсәләр, шуңа ияләшәләр, үзләренә шундый таләп куялар, матурлыкка омтылалар. Без исә сабыйларның Кеше булуга ясаган беренче адымнарында, киләчәккә салынган нигезендә тырышлыгыгыз өчен сезгә зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Бәйрәм белән ихластан тәбриклибез. Бары уңышлар һәм иҗади биеклекләр сезгә. Һәрвакыт шулай елмаюга юмарт, тәрбиягә оста, гүзәлеккә өндәүче булып калыгыз.

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***



**/Безнең уңышлар /**

## "Куркынычсыз тәгәрмәч"

Укучыларның юлда йөрү кагыйдәләре буенча булган белемнәрен тикшерү, юл хәрәкәте иминлеген үстерү, укучылар арасындагы юл-транспорт һәлакәтен кисәтү максатыннан соңгы елларда "Куркынычсыз тәгәрмәч" конкурсы уткәрелеп килә. Яшь инспекторлар конкурсы – бик тә әһәмиятле профилактика чарасы ул. Юл иминлеге мәсьәләсе елдан-ел катлаулана барган шартларда андый чаралар уздыру бигрәк тә кирәк. Ярышларда катнашу балаларга кызыграк булган саен, алар юлда йөрү кагыйдәләрен әйбәтрәк үзләштерәчәкләр һәм урамнарда үзләрен күпкә ышанычлырак хис итәчәкләр.

Быел да яңа уку елы башында юл хәрәкәте яшь инспекторларының район слеты оештырылды. Район ЮХИДИ бүлекчәсе базасында узган ярышларда барлыгы 10 команда катнашты. Балалар "Автошәһәрчек", "Юл кагыйдәләрен белүче", "Велосипедта фигуралы йөрү", "Беренче медицина ярдәме күрсәтү" конкурсларында көч сынаштылар. Нигездә, бәйгедә ел да бер үк мәктәпләр командалары яхшы чыгыш ясап, призлы урыннарга чыгалар. Ярыш нәтиҗәләре буенча безнең мәктәпнең ЮИД командасы мактаулы III урынны яулады.

"Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы" фонды һәм мәктәптән тыш эшләр үзәге оештырган бу бәйгедә барлык җиңүчеләргә Грамоталар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырдылар. Укучыларыбызга киләчәктә юл иминлеге буенча белем һәм күнекмәләрен тагын да арттырып, ярышларда зур уңышларга ирешүләрен көтеп калабыз.

***Мәктәпнең ЮИД җитәкчесе Руфия Гафиятуллина***

*/ТАССРның 100 еллыгына /*

## *XX гасыр башы авыл мәдрәсәсенең атналык укыту планы.*

Барыбызга да билгеле булганча, һәр уку елы башланыр алдыннан мәктәпнең **укыту планы** кабул ителә. Шул уңайдан, укытучыларда һәм укучыларда элеккеге авыл мәктәпләрендә укыту тәртибе кызыксындырырга мөмкин. Бу сорауга җавап табырга моннан ике ел элек безнең карамакка килеп эләккән бер тарихи документ ярдәм итә ала. Аны без Такталы авылы мәчетенә тапшырылган гарәп язулы иске китаплар арасыннан табып алдык. Документның оригиналы хәзерге вакытта Аксубай мәчете музеенда саклана. Ярты бит зурлыктагы бу кәгазьгә гади карандаш һәм шәмәхә төсле кара белән **“Дәресләрнең сәгатьләргә бүленүе”** дип исемләнгән җәдвәл (таблица) сызылган. Эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге документ мәдрәсәнең атналык укыту планыннан гыйбарәт. Датасы күрсәтелмәсә дә, аның 1911-1917-нче еллар арасына язылуын фаразларга мөмкин. Чөнки, архив материаллары күрсәткәнчә, 1911-нче елда Чистай өязендәге татар мәктәп-мәдрәсәләрендә әле рус теле укытылмаган. Ә бу планда рус теле аерым прндмет буларак күрсәтелгән.


Күләме ягыннан зур булмаса да, документ XX гасыр башы татар мәктәбенең эшчәнлегенә кагылышлы берничә мөһим фактны ачыкларга мөмкинлек бирә:

- элеккеге кадими ысулдан аермалы буларак, Такталы мәдрәсәсендә сыйныфларга бүленеш һәм дәрес-предмет системасы кертелгән булган (кадими мәдрәсәләрдә укыту индивидуаль ысул һәм бер китапны тәгәлләгәннән соң икенчесенә күчү тәртибе белән алып барылган);
- мәдрәсә **6 еллык** укыту программасы буенча эшләгән;
- балаларга дәресләр йөкләнеше яшь буенча арта барган (сәгатьләр саны хәзерге атналык йөкләнешкә туры килә диярлек);
- укыту программасының төп өлешен дөньяви эчтәлекле дәресләр алып торган, дин дәресләре сәгатьләрнең гомуми саны бары тик 13-22% гына тәшкил иткән;
- 1-3 сыйныфларда чагыштырмача иң күп сәгать ана теленә бирелгән;
- дин дәресләре, ана теле, хисаб (арифметика), табгыять (табигать белеме), шигырь уку, рәсем-кул эшләре, гимнастик (физкультура) дәресләре барлык сыйныфларда да кертелгән;
- рус теле 4-нче сыйныфтан керә башлаган, ләкин 4-6 сыйныфларда чагыштырмача иң күп сәгать бу фәнгә бирелгән;
- дөнья һәм Русия географиясе 4-нче сыйныфтан, милләт һәм Русия тарихы 5-нче сыйныфтан кертелгән;
- мәктәпнең эшчәнлеген тәэмин итү өчен, мәдрәсәдә ким дигәндә 6 укытучы-мөгаллимнең эшләве таләп ителгән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XX гасырның икенче унъеллыгында Такталы авылы мәдрәсәсендә укыту **җәдиди ысул** буенча алып барылган. Әйтергә кирәк, 1918-нче елга кадәр татар мәктәп-мәдрәсәләренең эшчәнлеге тулысы белән мәхәллә халкының иганәчелеге исәбенә генә алып барылган. Шуңа да карамастан, бу авылда укыту ул заман таләпләренә туры килерлек дәрәҗәдә оештырылган һәм алып барылган дип әйтә алабыз.

**Дәресләрнең сәгатьләргә бүленүе**

| Бары | Сыйныф 6 | Сыйныф 5 | Сыйныф 4 | Сыйныф 3 | Сыйныф 2 | Сыйныф 1 | Фән исемнәре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | 4 | 4 | 5 | 6 | 6 | 3 | Дин дәресләре |
| 37 | 3 | 3 | 4 | 9 | 9 | 9 | Ана теле |
| 30 | 4 | 4 | 4 | 6 | 6 | 6 | Хисаб |
| 12 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Табгыять |
| 4 | 2 | 2 | - | - | - | - | Тарих милли, руси |
| 6 | 2 | 2 | 2 | - | - | - | Җәгърафия гомуми, руси |
| 27 | 9 | 9 | 9 | - | - | - | Урыс теле |
| 12 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Рәсем, кул эшләре |
| 6 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Шигырь уку |
| 6 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Гимнастик |
| 168 | 30 | 30 | 30 | 27 | 27 | 24 | Барлыгы |



*Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты*

### *Матурлыкны күрә бел*

Ял итәргә рәхәт, диләр
Сездә табигать, диләр.
“Табигатьнең әчләрендә”
Ни барын тик белмиләр.

Ә мин менә сезгә әйтәм
Бер горурлану белән.
Авылымның матурлыгын
Күрдем мин хезмәт белән.

Печән чаптым әти белән
Яшел киң болыннардан.
Җиләк җыйдым әни белән
Гәрлинкә чокырыннан.

Көтү көттем абый белән
Чирмешәнгә сокланып.
Басуда шаулый игеннәр
Тордым шуңа шатланып.

Менә шулай хезмәттә
Ачыла бар матурлык.
Тик Туган җиргә генә
Була мондый якынлык.

***VII сыйныф укучысы***
***Самат Гафиятуллин***

## *Җәйге ялым – болында* */Укучылар иҗаты/*

Кемдер сагынып көтеп алган җәйге ялны берәр чит илдә, диңгез ярында, я булмаса телефоннан аерылмый үткәрергә дә мөмкин. Ә без җәй айларын гаиләбез белән болында үткәрәбез дисәк тә ялгыш булмас. Элек бакчабызда гына торган умарталарны әтием берничә ел элек күчереп куярга уйлады. Менә шул сәбәпле, гаиләбезнең һәр кешесенә җитәрлек хезмәте булган умартачылык эше болынга күчте. Болыныбыз авылның Мунчала күле дип аталган, авылдан бераз читтәрәк урнашкан җирендә. Биредә үзеңне әкияттәгедәй хис итәсең. Чөнки кошлар сайрый, әйләнә-тирәне агачлар һәм чәчәкләр чорнап алган, аланда төрле төскә буялган умарта оялары тезелеп киткән. Бер читтәрәк бал аерту, төрле кирәк-яракларны урнаштыру өчен корылма ясалган. Ә бал исе бөтен умарталыкка таралган була...



Авыл тормышының башка мәшәкатьлре дә җитәрлек, әлбәттә. Шулай да умарта асрау, аларны карый белү – әтием өчен һөнәр генә түгел, тормыш рәвеше. Ул моңа безне, дүрт баласын да, инандырды, хезмәтне яратырга, теләп башкарырга өйрәтте. Нәселебез өчен горурлык булган умарта үрчетү инде берничә буын бабамнан дәвам итә. Ә нәселдән-нәселгә килгән эш аеруча да үзенчәлекледер, минемчә. Бу һөнәрнең серләрен буыннан-буынга күчерү дә әтием өчен бер горурлык булып тора.

Укытучылык эшеннән тыш мондый хезмәтне алып бару җиңелләрдән булмаганын аңлап, аңа барыбыз да булышабыз. Җәйге ял вакыты шушы болында умарталарның хезмәт җыры тыңлап, бал исен иснәп үтә. Авызда тәмле бал булганчы, хезмәтеңнең нәтиҗәсен күргәнче - аның чагуыннан курыкмый карыйсы, аерган күчен җыясы, бу вакыт һәр ояга, һәр минут игътибар бирәсе бар шул. Күз куркак булса да, кул батыр дигәндәй, кулдан килмәс эш юк, һәрбер эш мөмкин диеп нәтиҗә ясау кирәк. Нинди генә авыр, вак мәшәкате бер-бер артлы тезелеп торган эш булса да, нәтиҗәсе бар. Бай булмасаң да, мохтаҗ булмый икән һәнәрле, эш белгән кеше.

***IX сыйныф укучысы Әминә Туктамышева***




## */Котлыйбыз!/*

10-нчы сентябрь көнне мәктәбебезнең иң өлкән укытучыларының берсе булган **Гафиятуллина Зөлфия апага 55 яшь тулды.**

Хөрмәтле Зөлфия апа! Сезне барча мәктәп коллективы һәм укучылар исеменнән гомер бәйрәмегез белән котлыйбыз. Ничәмә-ничә буын сабыйларга әлифбадан хәреф өйрәтеп, кулларыннан тотып яздырып, белем юлына алып кергәнсез. Укучылары төгәллеккә, тәртипкә, мөстәкыйльлеккә дә өйрәткәнсез. Таләпчән укытучыбызга озын гомер, сәламәтлек, гаилә иминлеге, оныклар шатлыгы, хезмәт уңышлары телибез.

9-нчы сентябрьдә җитәкчебез **Насыйров Рафик абыйның** да гомер бәйрәме. Аңа да гаилә иминлеге, корычтай нык сәламәтлек, алдагы елларда да мәктәп һәм авыл өчен зур эшләр башкаруын теләп калабыз.

Узган айда V сыйныфтан **Мамаева Ангелинаның** (27-нчы сентябрь), VI сыйныфтан **Минакова Әдиләнең** (10-нчы сентябрь), IX сыйныфтан **Мөхәммәтова Рузиләнең** (14 сентябрь) туган көннәре булып узды. Аларны да туган көннәре белән котлап, укуларында уңышлар, тырышлык, сәламәтлек телибез.

### *Табышмак әйтәм , тыңла*

Баштан башлап укысаң да,
Арттан башлап укысаң да,
Кая башлап укысаң да,
Һаман да шул бер үк сан.

---

Уңга таба мин һәркемнең
Иң яраткан кешесе;
Сулга таба –тегү егә
Олысы һәм кечесе.

## */Күңелле тәнәфес/*

### *Кызыклы сорауларга җавап бир*

- Бер авыл кешесе ат җигеп калага барган. Барып җиткәч, иң башлап ни дигән?
- Нәрсәне йомык күз белән дә күреп була?
- Кәҗәгә җиде яшь тулгач нишли?
- Кайсы елда кешеләр күбрәк ашый?
- Адәм башына нәрсә куна?
- Кешегә иң якын әйбер нәрсә?
- Нәрсәне күрү иң җиңел?

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Сара Насыйрова
Виктория Нукина
Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина